КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МӘДӘНИ МИРАС
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.06.2024 244-П

Казан

Мәдәни мирас объектларын югалтмау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклауны тәэмин итү юнәлешендәге дәүләт хезмәте күрсәтү өлкәсендәге аерым административ регламентларгаа үзгәрешләр кертү турында

Мәдәни мирас объектларын югалтмау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклауны тәэмин итү юнәлешендәге дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерам:

1. Мәдәни мирас объектларын югалтмау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклавны тәэмин итү юнәлешендәге дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада үзгәтелеп бирелгән аерым административ регламентларын расларга.

2. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын саклау
комитетының
18.06.2024 елгы 244-П номерлы
боерыгы белән расланды

Мәдәни мирас объектларын югалтмау, алардан файдалану, аларны популярлаштыру һәм дәүләт тарафыннан саклауны тәэмин итү юнәлешендәге дәүләт хезмәте күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелгән үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы 2022 елның 26 августында нәшер ителгән 263-П номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2002 елның 25 нче июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы “Россия Федерациясе халыклары мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре”, 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 нче февралендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм кабул итү тәртибен раслау” карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының административ регламентларны төзү һәм раслау тәртибе, Россия Федерациясе мәдәният Министырлыгының 2021 елның 13 декабрендәге 2089 номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү формасын һәм Мәдәни мирас объектларын саклауның федераль һәм региональ органнары тарафыннан бирү тәртибен раслау" боерыгы нигезендә боерам:»

4 нче пункттагы «М.М. Вәлиуллин» сүзләрен «Г.Ф. Камалетдиновага» сүзләренә алмаштырырга;

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентында:

3.5.2.1 пункттагы унберенче абзацның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Оештырылган сорауны форматлы-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гариза тутыручы электрон формага мәгълүмат

керткәндә, оешманың аерым таләпләре нигезендә башкарыла”

кушымтаны (белешмә) үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 2022 елның 26 августындагы 263-П номерлы боерыгына «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) Бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларының булуы яисә булмавы турында белешмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында, һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган җир, Төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре (Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән эшләрдән тыш) һәм башка эшләр йогынтысына дучар булган җирләрдә ачыкланган мәдәни мирас объектларының" түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

преамбуладагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.02.2022 № 175 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында " 28.02.2022 ел, № 175 карары белән» сүзәренә;

4 нче пункттагы «М.М. Вәлиуллин» сүзләрен «Г.Ф. Камалетдиновага» сүзләренә алмаштырырга.;

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары булуы яисә булмавы турында, һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясында каралган җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләре (Россия Федерациясе Урман кодексының 25 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән эшләрдән тыш) һәм башка эшләр йогынтысына дучар булган җирләрдә ачыкланган мәдәни мирас объектларын турында белешмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентында:

3.5.2.1 пункттагы унберенче абзацның беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Оештырылган сорауны форматлы-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гариза тутыручы электрон формага мәгълүмат керткәндә, оешманың аерым таләпләре нигезендә башкарыла.";

кушымтаны (белешмә) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 2022 елның 7 нче сентябрендә нәшер ителгән 275-П номерлы «Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Татарстан Республикасы

территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында»гы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуладагы "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе, расланган" сүзләрен төшереп калдырырга;

4 нче пункттагы «М. М. Вәлиуллин» сүзләрен «Г. Ф. Камалетдиновага» сүзләренә алмаштырырга;

Мәдәни мирас объекты билгеләренә ия объектны Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентында:

3.5.2.1 пунктында унберенче абзацның беренче җөмләсен
түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Оештырылган сорауны форматлы-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гариза тутыручы электрон формага мәгълүмат керткәндә, оешманың аерым таләпләре нигезендә башкарыла»;

3.7.1 пунктында дүртенче абзацтагы «27 календарь» сүзләрен «20 эш» сүзләре белән алыштырырга;

3.7.2 пунктында җиденче абзацтагыда «30 календарь» сүзләрен «22 эш» сүзләре белән алмаштырырга;

кушымтаны (белешмә) үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау Комитетының 2022 нче елның 8 нче ноябрендә нәшер ителгән 420-П номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын яки ачыкланган мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкару турында хисап документациясен раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау хакында»гы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуладагы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 нче февралендәге 175нче номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын әзерләү һәм раслау тәртибе белән» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 нче февралендәге 175нче номерлы карары белән расланган «Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм кабул итү тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану хакында " сүзләре белән алмаштырырга;

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи

һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектын ачыклау, яисә саклап калу эшләрен башкару турында хисап документациясен раслау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

3.5.1.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац белән тулыландырырга:

"Оештырылган сорауны форматлы-логик тикшерү бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә, гариза тутыручы электрон формага мәгълүмат керткәндә, оешманың аерым таләпләре нигезендә башкарыла. Дөрес тутырылмаган электрон гариза ачыкланганда, мөрәҗәгать итүчегә хатаның характеры һәм аны төзәтү тәртибе турында мәгълүмати хәбәр элетрон формның үзендә үк хәбәр ителә .

кушымтаны (белешмә) үз көчен югалткан дип танырга.